**«РАСЛЫЙМ»**
**Татарстан Республикасы**
**мәгариф һәм фән**
**министры**
**___________ И.Г.Һадиуллин**
**«___» _________ 2022 нче ел**

# Туган телдә белем бирү оешмалары укучылары өчен 2023 нче елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материалларының күрсәтмә варианты

# Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения в 2023 году государственной итоговой аттестации (ГИА) по родному (татарскому) языку для учащихся образовательных организаций с родным языком обучения

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# Туган телдә белем бирү оешмалары укучылары өчен 2023 нче елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе

## 2023 нче елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе уздыру өчен күрсәтмә материалларга аңлатмалар

2023 нче елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе уздыру өчен күрсәтмә материаллар белән танышканда, шуны истә тотыгыз: тәкъдим ителгән материаллар тикшереләчәк эчтәлекнең барлык элементларын да чагылдырмыйлар. 2023 нче елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе уздыру вакытында тикшерелергә мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе уздыру өчен әзерлек дәрәҗәсенә куйган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторында тәкъдим ителгән.

Күрсәтмә вариант туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен узучыларга һәм киң җәмәгатьчелеккә тестның структурасы, биремнәр саны, аларның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында гомуми күзаллау бирә. Бу варианттагы киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәрне үтәүнең бәяләү критерийлары киңәйтелгән җавапның тулылыгы һәм дөрес язылышы таләпләре турында күзаллау тудыра.

Бу мәгълүматлар туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе узуга әзерлек осталыгын булдырачак.

## Эш үтәү өчен күрсәтмә

Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының 9 нчы сыйныфын тәмамлаучы укучылар өчен, туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясенә 3 сәгать 55 минут (235 минут) вакыт бирелә. Биремнәр 3 бүлектән тора.

**Беренче бүлек** 1 биремнән тора. Анда 2 тапкыр **тыңланган** текстның кыскача эчтәлеге (изложение) язылa. Бирем 2 нче номерлы җавап бланкында эшләнә.

**Икенче бүлек** 7 биремнән тора (2-8 биремнәр). Биредә сүз, җөмлә, текстка төрле типтагы анализ күзаллана.

2-8 нче биремнәрнең җаваплары сүз яки цифрлар белән бирелә. Аларны 1 нче номерлы җавап бланкына язарга кирәк.

**Өченче бүлектәге** биремнәр укучылар 2 нче бүлектә укыган текст нигезендә башкарыла. Эшли башлаганчы, тәкъдим ителгән (9.1 һәм 9.2) биремнәрнең берсен сайларга һәм үз фикереңне дәлилләп, эзлекле рәвештә киңәйтелгән җавап бирү кирәк. Бирем 2 нче номерлы җавап бланкында эшләнә.

Биремнәрне үтәгәндә, орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

Биремнәрне эшләгәндә, караламадан файдаланырга мөмкин, әмма андагы язулар тест эшенә билге куйганда исәпкә алынмый.

Биремнәрне тәкъдим ителгән эзлеклелектә эшләргә киңәш ителә. Җавап бирергә авырсынган бирем очраса, аны калдырып, башкаларын эшли торырга мөмкин. Вакыт кала икән, аларны яңадан уйлап, эшләп карарга мөмкинлек туа.

Үтәлгән биремнәр өчен куелган баллар бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремгә дөрес җавап биреп, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

Эшне тәмамлагач, һәр җавапның 1 нче һәм 2 нче номерлы бланкларга дөрес номер белән куелганлыгын тикшерергә онытмагыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

## I бүлек

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

**1** Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез.

Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложениенең күләме 70 сүздән ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## II бүлек

***2 – 8 нче биремнәрнең җавабы сүз яки цифрлар булырга мөмкин. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка <u>буш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз</u> күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны, бланктагы үрнәктә күрсәтелгәнчә, аерым шакмакка языгыз.***

**2** Текстны укыгыз.

1) Шуны хәтерлим: җәйге җылы, кояшлы көн иде. 2) Су буенда төркем-төркем ап-ак казлар йөри. 3) Таллар яшел. 4) Таулар яшел. 5) Ярлар яшел. 6) Безнең бакча башында төбе ташлы сай гына елга ага. 7) Әнкәй белән җитәкләшеп, елганың икенче ягына – әрәмәгә чыгабыз. 8) Су уртасына җиткәч, ни өчендер әнкәй миңа иелеп карады. 9) Шул вакыт мин аның зур күзләрен күрдем. 10) Күзләре яшел икән, яшел талларга, ярларга, тауларга охшаган. 11) Аның күзләре яшел җәйнең яшел күзләре кебек.

*(Рөстәм Мингалимнән)*

Җөмләләрнең **оештыручы үзәкләре (грамматик нигезләре, баш кисәкләрен)** дөрес күрсәтелгән очракны билгеләгез. Җавап номерын языгыз.

1) казлар йөри (2 нче җөмлә)
2) бакча башында (6 нчы җөмлә)
3) елганың икенче ягына (7 нче җөмлә)
4) күзләрен күрдем (9 нчы җөмлә)
5) яшел күзләре кебек (11 нче җөмлә)

Җавап: _______________ .

**3** Текстны укыгыз.

**Ирен гармониясе** күзәтелгән сүзләр кулланылган җөмләне табыгыз. Җавап номерын языгыз.

1) Алсу күлдә алсу кошлар йөзә. 2) Менә алар икесе ике якка аерылып китәләр дә, кинәт кенә, бер-берсенә каршы килә башлыйлар. 3) Бераздан аккошлар, бөтенләй якынлашып, томшыкка томшык килеп терәләләр, гүя исән-имин туган якларына кайту шатлыгын уртаклашалар, үзләренчә тәбрикләшәләр. 4) Ул да булмый, быргы авазлары чыгарып кычкыра башлыйлар.

Җавап: ________________ .

**4** Текстны укыгыз.

**Өтерләр** куелырга тиешле җөмләләрне табыгыз. Җавап номерларын языгыз.

1) Фәрит Разия апасы белән бакчага чыкты. 2) Бакчада чәчәкләр бик күп. 3) Шул чәчәкләргә төрле-төрле күбәләкләр килеп куна. 4) Эх нинди ямьле соң җәй!

5) Разия энесенә чәчәкләрне өзмәскә агачларны сындырмаска куша. 6) Үзе чәчәкләр җыеп кайта һәм аларны китап арасына салып киптерә. 7) Аларны ап-ак кәгазьләргә ябыштыра. 8) Разия күбәләкләрне һәм төрле-төрле бөҗәкләрне дә тотып кайта.

Җавап: ________________ .

**5** Текстны укыгыз.

**Ясалма сыйфатны** табып языгыз.

Көн артыннан көн үткән, кояшлы яз килгән. Үләннәр яшәреп киткәннәр, агачлар чәчәкләргә күмелгәннәр. Бары куак кына язны котлап елмая алмаган. Ул, суыктан чирләгәнгә, кара янып, тереклектән мәхрүм булып боегып утырган да утырган.

Җавап: ________________ .

***Текстны укыгыз һәм 6-9 нчы биремнәрне үтәгез.***

1) Кар дөньясында Фирүзә исемле кар бөртеге оча иде.

2) Кар дөньясын тутырып очкан кар бөртекләре чиксез галәм океанында сәяхәт кылып йөргән йолдызлар санынча. 3) Кем белә, бәлки, аннан да күбрәктер. 4) Шул ыгы-зыгыда, шул буталышта ничек танырсыз икән, кадерле дусларым, Фирүзәне?

5) Ә сез, тәңкә карлар талгын гына тирбәлеп очканда, һавага карагыз. 6) Күрдегезме, дусларым? 7) Бер кар бөртеге тирбәлде-тирбәлде дә читкә очып китте, җиргә кунам-кунам дип, түбән төште-төште дә, җил канатларына утырып, янә югарыга омтылды. 8) Аксыл болытлар арасыннан күз сирпегән кояш яктысында ялтырап алды да үзе шикелле үк шаян, җитез кар бөртекләре арасына кереп югалды.

9) Әллә күрми дә калдыгызмы? 10) Фирүзә шул иде бит инде. 11) Әйе, көмеш керфекле, ефәк чәчле, ачык йөзле кар бөртеге Фирүзә шул иде. 12) Кая бара, кая оча соң ул Фирүзә, дисезме? 13) Үзе дә белми кая очканын, кай тарафларда йөзгәнен. 14) Күк океаны чиксез, күк юллары озын, җил канатлары җитез.

15) Әллә сез үзенең кая очканын белергә теләми дип уйлыйсызмы Фирүзәне? 16) Һи, теләмәгән кайда ул! 17) Тик аның тирә-ягындагы өлкән кар бөртекләре бик җитдиләр шул, һич кенә дә иплән сөйләшергә теләмиләр Фирүзә белән.

18) Очты-очты да, йөзде-йөзде дә Фирүзә янәшәдән генә очып барган өлкән кар бөртегенә эндәште:

– Абзыкаем, әйтче, зинһар, шулай ашкынып, дәртләнеп кая очабыз без?

19) – Урманнарны агартырга, тауларны яңартырга, басуларны җылытырга.

20) Фирүзә түбән карады.

21) – Ә нишләп төшмибез?

22) – Җирдә һәркайсыбызның үз урыны бар. 23) Шул урынга барып җиткәч тә төшәрбез. 24) Барыбыз бергә түгел, берәм-берәм төшәрбез. 25) Берәм-берәм төшмәсәк, җиргә кар тигез ятмый. 26) Кар тигез ятмагач, җир җылынмый. 27) Җир җылынмагач, игеннәр уңмый. 28) Игеннәр уңмагач, икмәк булмый. 29) Икмәк булмагач, балалар куанмый. 30) Балалар куанмагач, кар дөньясының кызыгы бетә. 31) Безнең иң олы максатыбыз – балаларны куандыру.

32) Фирүзә беркавым, шат йөзле балалар һәм кызыгы беткән дөнья турында уйлый-уйлый, сүзсез генә очты. 33) Аннары йомшак иреннәрен турсайтып болай диде:

– Ә минем бүген үк, хәзер үк шатландырасым килә балаларны.

34) – Алайса, – диде арадан бер өлкәнрәге, – син, сеңелкәем, ә-әнә теге тау битенә төшеп кунарсың. 35) Ә-әнә, күрәсеңме, балалар чаңгы шуалар. 36) Син төшеп кунгач, тау биегәебрәк китәр. 37) Тау биегәйгәч, балалар шатланырлар.

38) – Минем сезнең кебек шатландырасым килми балаларны, минем үземчә шатландырасым килә, – дип, әле бер кар бөртеге, әле икенчесе янына очып килде Фирүзә.

39) – Безнең дә үзебезчә шатландырасыбыз килә дә бит аларны, тик кар дөньясының кагыйдәләре һәммәбез өчен дә бертөрле шул, – дип көрсенделәр кар бөртекләре.

40) – Бер генә баланы булса да үземчә шатландырыр идем, үземчә, – дип такмаклады Фирүзә һаман.

41) – Мондый холкың белән тиз эрерсең син, ашкынма алай, башкалар эшләгәнне генә эшләргә тырыш, – дип үгетләп карадылар Фирүзәне өлкән кар бөртекләре.

42) – Юк, юк, юк, – дип, һаман үз сүзен сөйләде Фирүзә, – эресәм эрермен, әмма теләгемә ирешермен. 43) Мин бик телим бит, бик теләгәч, теләгем үтәлергә тиеш минем.

*(Ф. Шәфигуллиннан*)*

**Фаил Шәфигуллин* (1939-1982) – танылган шагыйрь һәм прозаик.

**6** **Текстның эчтәлегенә туры** килгән җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Кар бөртекләре кыш җитүен хәбәр итәләр.
2) Фирүзә – бик шаян һәм тырыш кыз.
3) Кар бөртекләренең иң зур максаты – балаларны куандыру.
4) Кар бөртеге Фирүзә тиз арада тау битенә очып төшеп эреде.
5) Фирүзә еларга кереште.

Җавап: ________________ .

**7** **Фразеологик әйтелмә** кулланылган җөмләне күрсәтегез. Җавап номерын языгыз.

1) Кая бара, кая оча соң ул Фирүзә, дисезме?
2) Тик аның тирә-ягындагы өлкән кар бөртекләре бик җитдиләр шул, һич кенә дә ипләп сөйләшергә теләмиләр Фирүзә белән.
3) Җир җылынмагач, игеннәр уңмый.
4) Ә минем бүген үк, хәзер үк шатландырасым килә балаларны.
5) Юк, юк, юк, – дип һаман үз сүзен сөйләде Фирүзә, – эресәм эрермен, әмма теләгемә ирешермен.

Җавап: ________________ .

**8** 9-14 нче җөмләләрдән ***якларда*** сүзенең синонимын табып, күчереп языгыз.

Җавап: ___________ .

***2-8 нче биремнәрнең җавапларын, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга һәм җавапның бирем номеры күрсәтелгән юлга язылуын тикшерергә онытмагыз.***

## III бүлек

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 9.1 яки 9.2 нче биремнәрнең бары тик берсен генә сайлап алып, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**9.1** **Икмәк булмагач, балалар куанмый. Балалар куанмагач, кар дөньясының кызыгы бетә. Безнең иң олы максатыбыз – балаларны куандыру, -** җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез.

Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

**9.2** **Теләгеңәирешү** әйтеменең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? “**Теләгеңә ирешү өчен, нәрсә эшләргә кирәк?**” темасына сочинение языгыз. Фикерегезне языгыз. Раслау өчен, укылган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

***Һәрбер җавапның бирем номеры күрсәтелгән юлга язылуын тикшерергә онытмагыз.***

## Туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен бәяләү системасы

## I бүлек

| *Тыңлау өчен текст* |
|---|

### Ипекәй

Мин үзем икмәкне кеше өчен иң зарури ризык итеп кенә түгел, ә илнең иң зур байлыгы, дәүләтнең төп куәте дип тә саныйм. Чыннан да, илдә, дәүләт кулында икмәк җитәрлек булмаса, халык тук, бөтен яши алыр идемени, дәүләт башка байлыкларын бүтән ихтыяҗларга тота алыр идемени?..

Халык икмәкнең кадерен кытлык елларда гына түгел, һәрвакытта, иң уңган чакларында да бик яхшы белгән. Ул аны юкка-барга әрәм-шәрәм итмәгән, саклап тоткан, ничек тә запас белән торырга тырышкан. Безнең татар халкында исә икмәккә хөрмәт аеруча зур иде. “Ипекәй” дип кадерләп кенә йөртә иде ул аны...

Әгәр урамда ипи сыныгы ятканын күрсә, ул аны, иренмичә иелеп алып, читәнгә яки бүрәнә ярыгына кыстырып китә. Балаларга да: “Сыныгыңны калдырма, валчыгыңны җый, бәрәкәт очмасын”, - дип, әйтеп кенә торалар. Һәм без ипи валчыгын таптаудан, чынлап та, курка идек, икмәк безгә рәнҗер, бездән китәр, килмәс дип шомлана идек... Хәзер алай шомланулар бетте, әмма хөрмәт калырга, хөрмәт сакланырга тиеш.

*(Ә.Еникидән)* ***(148 сүз)***

### 1 нче биремне бәяләү критерийлары

*1 нче таблица*

| **Кыска изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Икмәк - илнең зур байлыгы, дәүләтнең төп куәте. |
| 2 | Халык икмәкнең кадерен һәрвакыт яхшы белгән. |
| 3 | Икмәккә хөрмәт сакланырга тиеш. |

**Язма эшне бәяләү критерийлары**

*2 нче таблица*

| № | Критерий | Балл |
|---|---|---|
| **ИК1** | **Изложениенең эчтәлеге** | |
| | Укучы тыңлаган текстның эчтәлеген тулы ачкан, анда яктыртылган **барлык** мәсьәләләр язмада урын алган. | 2 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган,<br>**әмма** бер микротема төшеп калган (яки өстәлгән). | 1 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган,<br>**әмма** бердән артык микротема төшеп калган (яки өстәлгән). | 0 |
| **ИК2** | **Башлангыч текстны җыйнакландыру** | |
| | Укучы текстның гомуми эчтәлеген бер яки берничә алым белән кыскарткан, җыйнакландырган | 3 |
| | Бер яки берничә алым белән текстның ике микротемасын җыйнакландырган | 2 |
| | Бер яки берничә алым белән текстның бер микротемасы җыйнакландырылган | 1 |
| | Текстны җыйнакландыру өчен бер алым да **кулланылмаган** | 0 |
| **ИК3** | **Изложениенең мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелеге** | |
| | Укучының эшендә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә:<br>- логик хаталар юк, эзлеклелек бозылмаган;<br>- текст кызыл юлларга дөрес бүленгән | 2 |
| | Эштә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә,<br>**әмма** бер логик хата бар<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә бер хата бар | 1 |
| | Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган,<br>**әмма** бердән артык логик хата<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә ике хата җибәрелгән | 0 |
| **ИК1-ИК3 күрсәткечләре буенча изложение өчен җыела торган иң югары балл** | | **7** |

## II бүлек
## 2 – 8 нче биремнәрне тикшерү

Икенче бүлектәге һәр биремгә дөрес җавап биргән өчен укучыга **берәр балл** куела. Җавап инструкциядә күрсәтелгәнчә эшләнсә һәм тулысынча тиешле җавап белән тәңгәл килгән очракта, дөрес үтәлгән дип исәпләнә. Җавап ялгыш булса яки бөтенләй булмаса, **0 балл** куела.

*3 нче таблица*

| Биремнәр | Җаваплар |
|---|---|
| 2 | 1 |
| 3 | 3 |
| 4 | 45 |
| 5 | кояшлы |
| 6 | 3 |
| 7 | 5 |
| 8 | тарафларда |

## III бүлек

### 9 нчы биремне тикшерү критерийлары
### 9.1 нче биремне бәяләү критерийлары
### 9.1 биременә җавап түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә.

*4 нче таблица*

| № | Текст эчтәлеген анализлауга бәйле темага язылган сочинениене (9.1) бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| $C_1$К1 | **Тексттан алынган кисәкнең мәгънәсен аңлау** | |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлаткан. Аңлатмада хаталар юк. | 2 |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген гомумән дөрес аңлаткан, **ләкин** аңлатмада 1 хатасы бар. | 1 |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлатмаган, **яки** имтихан бирүче, тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген аңлатканда, 2 яки күбрәк хата ясаган, **яки** тексттан алынган кисәк эчтәлегенең аңлатмасы язма эштә юк. | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| $C_1K2$ | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Имтихан бирүче текстан әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 2 дәлил-мисал китергән. | 3 |
| | Имтихан бирүче текстан әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Имтихан бирүче башка текстан дәлил-мисаллар (-лар) китергән. | 1 |
| | Имтихан бирүче әлеге кисәкнең эчтәлеген аңлата торган дәлил-мисал китермәгән,<br>**яки** имтихан бирүче биремдәге цитатаны я аның бер өлешен дәлил-мисал итеп китергән. | 0 |
| $C_1K3$ | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм эзлеклелек белән характерлана,<br>**ләкин** 1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки** абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин** логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| $C_1K4$ | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән,<br>**ләкин** текст төзүдә 1 хатасы бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар. | 0 |
| **$C_1K1$-$C_1K4$ критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **9** |

**Игътибар!**

Әгәр сочинениедә текст күчереп кенә язылса яки анда текстның эчтәлеге генә чагылыш тапса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча ($C_1K2$-$C_1K4$) **0 балл** белән бәяләнә.

Әгәр сочинениедәге текст фрагменты 9.1 дәге текстан алынмыйча, башка текстан алынса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча ($C_1K2$-$C_1K4$) **0 балл** белән бәяләнә

**Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге** аерым бәяләнә (6 нчы таблицаны кара).

## 9.2 нче биремне бәяләү критерийлары

**9.2 биремenә җавап түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә.**

*5 нче таблица*

| № | Текст эчтәлеген анализлауга бәйле темага язылган сочинениене (11.2) бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| **С$_3$К1** | **Тексттан алынган кисәкнең мәгънәсен аңлау** | |
| | Имтихан бирүче (сочинениенең теләсә кайсы өлешендә теге яки бу формада) аңлатма биргән һәм киңәйтелгән формада тасвирлаган. | 2 |
| | Имтихан бирүче (сочинениенең теләсә кайсы өлешендә теге яки бу формада) аңлатма биргән,<br>**ләкин** киңәйтелгән формада тасвирламаган. | 1 |
| | Имтихан бирүче ялгыш аңлатма биргән,<br>**яки** төшенчәгә аңлатмасы язма эштә юк. | 0 |
| **С$_3$К2** | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Имтихан бирүче 2 дәлил-мисал китергән, шуларның берсе укылган тексттан, икенчесе – тормыш тәҗрибәсеннән<br>**яки** имтихан бирүче 2 дәлил-мисал китергән, шуларның икесе дә укылган тексттан. | 3 |
| | Имтихан бирүче укылган тексттан 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Имтихан бирүче тормыш тәҗрибәсеннән дәлил-мисаллар (-лар) китергән. | 1 |
| | Имтихан бирүче бер генә дәлил-мисал да китермәгән. | 0 |
| **С$_3$К3** | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм эзлеклелек белән характерлана,<br>**ләкин** 1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки** абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин** логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки** абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| **С$_3$К4** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән,<br>**ләкин** текст төзүдә 1 хатасы бар. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар. | 0 |
| **$С_3$К1-$С_3$К4 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **9** |

**Игътибар!**

Әгәр сочинениедә текст күчереп кенә язылса яки анда текстның эчтәлеге генә чагылыш тапса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча ($С_3$К2-$С_3$К4) **0 балл** белән бәяләнә.

Әгәр сочинение 9.2 дәге сүз яки гыйбарәгә туры килмәсә, бәяләүнең барлык критерийлары буенча ($С_1$К2-$С_1$К4) **0 балл** белән бәяләнә.

Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге аерым бәяләнә (6 нчы таблицаны кара).

*6 нчы таблица*

| № | Укучы сөйләменең грамоталылыгын һәм фактик төгәллеген бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| **ГК1** | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк **яки** хатасы 1 дән артык түгел | 2 |
| | 2-3 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| **ГК2** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3-4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ГК3** | **Грамматик нормаларның үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк **яки** 1 хатасы бар | 2 |
| | 2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 3 тән артык | 0 |
| **ГК4** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләм хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3–4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ФК1** | **Язма сөйләмнең фактик төгәллеге** | |
| | Материалны язмада бирүдә, шулай ук аңлауда һәм терминнар кулланылышында фактик хаталар юк | 2 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 1 хата бар | 1 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 2 хата бар | 0 |
| **ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **10** |

Грамоталылыкны бәяләгәндә, **изложение һәм сочинениенең күләмен** исәпкә алырга кирәк.

6 нчы таблицада китерелгән нормативлар гомуми күләме 140 тан артык сүз булган изложение һәм сочинениеләрне тикшерү өчен кулланыла.

Әгәр **изложение һәм сочинениеләрнең** гомуми күләме 70-139 сүз булса, ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча 1 баллдан артык куелмый:

ГК – 1 буенча орфографик хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК – 2 буенча пунктуацион хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК – 3 буенча грамматик хаталар булмаганда 1 балл куела;

ГК – 4 буенча сөйләм хаталары булмаганда 1 балл куела.

ФК1 – буенча фактик хаталар һәм терминнар кулланылышында хаталар булмаганда 1 балл куела.

Әгәр **изложение һәм сочинениеләрнең** гомуми күләме 69 гына сүз булса, мондый эшләргә ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча 0 балл куела.

Әгәр укучы иҗади эшнең бары тик берсен генә (я изложение, я сочинение) үтәсә, ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча бәяләү шулай ук эшнең күләменнән чыгып башкарыла:

Әгәр эш 140 яки аннан артыграк сүздән торса, грамоталылык 6 нчы таблица нигезендә бәяләнә.

Эшнең күләме 70-139 сүздән торса, ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча 1 баллдан артык куелмый (югары күрсәтелгәнчә).

Әгәр эшнең күләме 69 сүздән артмаса, мондый эшләргә ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча 0 балл куела.

Дәүләт йомгаклау аттестациясен тулаем башкару барышында җыярга мөмкин булган максималь балл – **33.**

**Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0-14 балл – «2» ле билгесе;

15-22 балл – «3» ле билгесе;

23-28 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының ГК1-ГК4 критерийлары буенча баллары 4 тән кимрәк булмаска тиеш.

29-33 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының ГК1-ГК4 критерийлары буенча баллары 6 дан кимрәк булмаска тиеш.